ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.10.2024 г.Лениногорск № 1289

Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 5 пунктының икенче абзацы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Уставы нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Тәкъдим ителгәнне расларга:

2024 елның 1 октябреннән 2024 елның 31 декабренә кадәр махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибе (1 нче кушымта);

Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер мәртәбә акчалата түләүне билгеләү буенча комиссия турында нигезләмә (алга таба-Комиссия) (2 нче кушымта);

2. Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзүдә ярдәм иткән затларга өстәмә социаль ярдәм чарасы күрсәтү комиссиясе составы (3 нче кушымта).

3. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитетын махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт

төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер мәртәбә бирелә торган түләүне оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

4.«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына тиешле елга бюджет язмасында җирле бюджет акчалары исәбеннән каралган акчалар чикләрендә бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләү бирүгә бәйле чыгымнарны башкарырга.

5.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет сайтында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы М.Н. Гирфанов

Хәйбрахманов И.Р.
5-44-72